ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» июленнән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2024 елның 04 июнендәге 154 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемаларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы һәм «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2024 елның 04 июнендәге 154 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авылы территориясендә тундырма, баллы тәм-томнар һәм салкынча эчемлекләр сату буенча сезонлы сәүдә нокталары урнаштыру» бүлеген 1 нче кушамата нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә:

| № | Реестр | Адресы, урнашу урыны | Мәйданы, |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | номеры | | квадрат метрларда |
| 8 | Н-8 | Ленин урамы, 1В йорты (мәдәният һәм ял паркы) | 8 гә кадәр |
| 9 | Н-9 | Ленин урамы (җәяүлеләр зонасы) | 8 гә кадәр |
| 10 | Н-10 | Заливная урамы, 2 нче йорт (РМЙ янындагы парк) | 8 гә кадәр |
| 11 | Н-11 | Чернышевский урамы, 44а йорты (ЗАГС янындагы парк) | 8 гә кадәр |
| 11.1 | Н-11.1 | Ленин урамы, 1В йорты (мәдәният һәм ял паркы) | 8 гә кадәр |

1.2. 5 нче кушымтаны яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «04» июнендәге
154 номерлы карарына
кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Башкарма комитетының
2026 елның __ июлендәге ____ номерлы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә ав., Ленин урамы, 1 В йорт территориясендә (мәдәният һәм ял паркы территориясе) стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру картасы

.

